Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет майданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000,г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

# КАРАР

«26» декабрь 2023 ел № 3

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы, Арча шәһәр Советының 2022 елның 17 августындагы 73 номерлы карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән үзгәрешләр кертү проектын тикшерүдә катнашу өчен җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хуҗаларының, шәһәр җирлеге торак пунктларында яшәүчеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатыннан КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны 2024 елның 23 гыйнварына билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресы буенча 17.00 сәгатьтә уздырырга.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдим ителгән проект буенча гражданнарның тәкъдимнәре, искәрмәләре һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризалары 2024 елның 23 гыйнварына

кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресы буенча язма рәвештә җибәрелә дип билгеләргә (тел. 8(84366) 3-16-25).

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын тикшерү буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын кушымта нигезендә расларга.

5. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында Арча шәһәр Советы карары проектын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында «Җирлекләр» бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Касыймовка йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы И.Г.Нуриев

Арча шәһәре»
муниципаль берәмлеге башлыгының
26.12.2023 ел, № 3 карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын тикшерү буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Эшче төркем рәисе: | |
| Касыймов Р.Ф. | - Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Эшче төркем секретаре: | |
| Нигъмәтҗанова Г.Х. | -«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары; |
| Эшче төркем әгъзалары: | |
| Баһаветдинов Р.Р. | - Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Шакиров И.М. | - 12 нче Арча сайлау округы буенча депутат; |
| Минашаева Р.Р. | - 15 нче Арча сайлау округы буенча депутат; |
| Хасанов И.М. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |